

Иске Аллагол - Ковылкино районында бердәнбер татар авылы. Биредә ата-бабаларыбызнын гореф-гадәтләренә аерым хормәт белән карыйлар.
Кышын бу авылда, һәр ел диярлек, кырыктан артык кеше яши. Халык остәлендә һәрвакыт милли ризыклар һәм камыр ризыклары бар. Жирле халык рус һәм мордвалар белән һәрвакыт бергә дус яши.
Авыл энтузиасты Наилә Алимжан кызы Пугачева борынгы татар жырларын кvп белә. Республика татар мәдәнияте онлайн-фестивалендә катнашты һәм жинvчеләр исемлегенә керде. Әйтеп китәргә кирәк, ул торле-торле чараларда яратып катнаша. Кvптән тvгел ана рус, мордва һәм татар милли ашларын тәкъдим итv очен зур булмаган онлайн-диалог әзерләv идеясе килде.      Анын идеясен кvрше авыллардан килгән коллегалары да хуплады. Ниятләнгән эшләрне тормышка ашыруга әзерлек башланды инде. Бу районнын һәр авылында тошерелгән видео яки фотороликларда һәр милләт вәкиле vзенен традицион милли ризыклары турында сойләячәкләр, рецептлар һәм әзерләv серләре белән уртаклашачаклар, тра-дицияләр турында сойләячәкләр. Әгәр уй килеп чыкса, ботен материалны бер видеога жыячаклар. Кызганычка каршы, чикләvләр режимы уртак дустанә дегустация vткәрергә момкинлек бирми, әмма анысы әле алда. Мини-проектны рус, мордва һәм татар мәдәниятләренен дуслыгына багышлау планлаштырыла.